РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Решение Карар

№ 41/3 Чистай шәһәре 6 февраль 2019 ел

Чистай муниципаль районы
Советының 10.02.2017 елгы
“Җир участогын арендалау
килешүе төзү хокукына
аукцион предметының башлангыч
бәясен билгеләү турында”гы 17/5
нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Җир участокларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатында, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китереп, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 маддәсенең 14нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Советының 10.02.2017 елгы “Җир участогын арендалау килешүе төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында”гы 17/5 нче карарына 1нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:
“ авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки авыл хуҗалыгы файдалануындагы зона составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланылучы җирләргә карый торган шундый җир участогының кадастр бәясенең бер ярым проценты күләмендә.”

2. Әлеге карарны масса-күләм мәгълүмат чараларында – “Чистопольские известия” газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы                                                            Д.А. Иванов